| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**01.06.2017** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 1587** |

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск шәһәре, Туктаров урамы, 4/а йорты адресы буенча урнашкан җир кишәрлеген һәм анда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларын тартып алу турында» 2015 елның 03 декабрендәге 2665 номерлы карарының үз көчен югалтуын тану хакында

Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре Туктаров ур. 4/а йортын авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программадан чыгарылуга бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәр судының 2017 елның 01 февралендәге Дело 2-125/2017 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск шәһәре, Туктаров урамы, 4/а йорты адресы буенча урнашкан җир кишәрлеген һәм анда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларын тартып алу турында» 2015 елның 03 декабрендәге 2665 номерлы карарының үз көчен югалтуын танырга

2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Матвеевага әлеге карарның күчермәсен түбәндәгеләргә җибәрергә:

-күчемсез милеккә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алучы органга;

-«Зеленодольск муниципаль районының торак сәясәте департаменты» МКУ; торак урыннар милекчеләренә.

3. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының (http://pravo.tatarstan.ru ) хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) мәгълүмат сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Матвеевага йөкләргә.

Җитәкче А.Х. Сәхибуллин